**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы
авылы, Татарстан урамы, 17 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**№ 134** **2019 елның 24 апреленнән**

# К А Р А Р

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турындагы кушып бирелүче Кагыйдәне расларга.

1. Хезмәткәрләрнең әлеге карарга ярашлы төстә билгеләнгән хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләме сакланганда һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләре башкарылганда, 2019 елның 31 мартына түләнгән хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 апреленә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) вазифалары исемен әлеге карарга ярашлы төстә бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне муниципаль районның Татар Сараланы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Җитәкче** **И.Ф.Мөбарәкшин**